ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СУГУШЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СУГЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Центральная ул., дом 27, село Сугушла,
Лениногорский район, 423281

Центральный урамы, 27 нче йорт, Сугышлы
авылы, Лениногорский район, 423281

Тел.: (8-85595) 3-81-91, факс: (8-85595) 3-81-91, Sugush.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2021 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:
- урамнарны яктырту;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту;
- торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова